ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16 октябрь 2025 ел № 8374

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясының 2 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль яклау (ярдәм) чараларын, социаль хезмәтләрне, башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне билгеләү һәм бирү процессларын гамәлгә ашыруга төп таләпләрне раслау турында» 2024 елның 3 маендагы 564 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә ел саен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетын формалаштырганда, компенсация түләүләре бирү өчен кирәкле акчаларны күздә тотарга.

3. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2014 елның 15 гыйнварында «Челнинские известия» газетасының 2 нче санында бастырып чыгарылган «Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы Башкарма комитет Карарының 2 пункты;

2) 2014 елның 5 мартында «Челнинские известия» газетасының 16 нчы санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы Карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 17 февралендәге 944 номерлы Башкарма комитет Карары;

3) 2015 елның 25 ноябрендә «Челнинские известия» газетасының 86 нчы санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы Карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган

гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 18 ноябрендәге 6571 номерлы Башкарма комитет Карары;

4) 2016 елның 11 маенда «Челнинские известия» газетасының 33 нче санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы Карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 29 апрелендәге 2159 номерлы Башкарма комитет Карары;

5) 2017 елның 14 апрелендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2017 елның 31 маенда «Челнинские известия» газетасының 38 нче санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы Карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 6 апрелендәге 1955 номерлы Башкарма комитет Карары;

6) 2018 елның 20 мартында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2018 елның 21 мартында «Челнинские известия» газетасының 19 нчы санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы Карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 7 мартындагы 1180 номерлы Башкарма комитет Карары;

7) 2019 елның 24 октябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2019 елның 25 октябрендә «Челнинские известия» газетасының 79 нчы санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның «Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 22 октябрендәгеге 5404 номерлы Башкарма комитет Карары;

8) 2023 елның 22 февралендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы Карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 16 февралендәге 1020 номерлы Башкарма комитет Карары;

9) 2023 елның 29 мартында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы Карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 мартындагы 2092 номерлы Башкарма комитет Карары.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 16 октябрендәге
8374 номерлы карарына
кушымта

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган
муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга
компенсация түләүләрен бирү
тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре (алга таба – компенсация) билгеләү һәм түләү тәртибен, шартларын билгели.

2. Компенсация, гаиләнең җан башына уртача керемен исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениесе белән килешү төзегән һәм мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган тиешле муниципаль белем бирү учреждениесенә баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләве керткән законлы вәкилгә (ата-анага, уллыкка (кызлыкка) алучыга, опекунга) яки аның вәкаләтле затына (алга таба – гариза бирүче) билгеләнә һәм түләнә.

3. Компенсация алу хокукын билгеләгәндә, гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы Карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.

Компенсация билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме компенсация билгеләү турында гариза бирелә торган айга кадәрге ай алдыннан килүче соңгы 12 календарь ай (алга таба – хисап чоры) өчен гаилә әгъзаларының керемнәр суммасыннан чыгып билгеләнә.

Гаиләнең җан башына уртача керемен билгеләгәндә, аерым яки бергә яшәүләренә бәйсез рәвештә, компенсация алучының ире (хатыны) булган гражданнарның керемнәре исәпкә алына.

Хисап чорында гаиләнең җан башына уртача кереме гаиләнең уртача айлык гомуми керемен гаилә әгъзалары санына бүлү юлы белән исәпләнә.

Хисап чорында гаиләнең уртача айлык гомуми кереме гаиләнең барлык әгъзаларының уртача айлык керемнәре суммасына тигез.

Гаиләнең һәр әгъзасының уртача айлык кереме, аның хисап чоры дәвамында алган керемнәренең суммасын шушы хисап чорында әлеге керемнәрне алган айлар санына бүлү юлы белән билгеләнә.

4. Компенсация күләмен билгеләгәндә, гаилә составындагы түбәндәге әгъзалар исәпкә алына:

1) иждивениедә булган һәм 18 яше тулмаган, шул исәптән хастаханәләрдә, балалар санаторийларында дәваланучы балалар, шулай ук интернат-мәктәпләрдә карау өчен ата-аналары тарафыннан өлешчә түләү кертелгән балалар;

2) ата-аналары белән бергә яшәү фактына бәйсез рәвештә, уку йортына, шул исәптән дәүләтнеке булмаган белем бирү учреждениеләренә йөреп белем алучы 18 дән 23 яшькә кадәрге (никахта тормаган) затлар;

3) әгәр алар башка ата-ана гаиләсендә исәпкә алынмаган булса, гаиләдә яшәүче үги

малайлар һәм үги кызлар;

4) гражданнар гаиләләренә опекага алынган балалар;

5) тәрбиягә алган гаиләләрдә тәрбияләнүче тәрбиягә алынган балалар.

5. Ата-ананың икесе дә (ата яки ана – тулы булмаган гаиләдә) ата-аналар хокукыннан мәхрүм ителгән гаилә составындагы балалар яки тулысынча дәүләт тарафыннан тәэмин ителүче балалар исәпкә алынмый.

6. Компенсация күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

ДК= Ф х (100-МДД) – К, монда

ДК – компенсация күләме;

Ф – мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениесендә баланы карау һәм тәрбияләү өчен, Башкарма комитет карары белән расланган ата-ана түләве күләме чикләрендә фактта алына торган ата-ана түләвенең күләме;

МДД – мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениесендә баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенә гражданнар чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше (таблица нигезендә билгеләнә);

К – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларында баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация турында» 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы Карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениесендә баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация күләме.

Таблица

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениесендә баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенә гражданнар чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше

| Гаиләнең бер әгъзасына керем зурлыгы | Ата-ана түләвенә гражданнар чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше (процент) | | |
|---|---|---|---|
| | 1 балага | 2 балага | 3 балага |
| 10 000 сумга кадәр | 60 | 38 | 23 |
| 10 001 сумнан 15 000 сумга кадәр | 70 | 43 | 36 |
| 15 001 сумнан 20 000 сумга кадәр | 80 | 53 | 53 |
| 20 000 сумнан күбрәк | 100 | 100 | 100 |
| Яшәү минимумыннан түбәнрәк (күпбалалы гаилә өчен) | 0 | 0 | 0 |

## 2 бүлек. Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе

7. Гариза бирүчеләргә компенсация бирү, килешү нигезендә билгеләнгән халыкка социаль ярдәм чараларын тормышка ашыра торган оешма (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Компенсация алу өчен гариза бирүче вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

1) компенсацияне кредит оешмасы аша алган очракта, мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениесе белән килешү төзегән затның, кредит оешмасындагы шәхси счет номерын күрсәтеп, компенсация билгеләү турында гаризасы;

2) шәхесне раслаучы документның күчермәсе (күчермә нотариуста расланмаган булса, төп нөсхәсен күрсәтеп);

3) компенсация билгеләү турында гариза бирелә торган айга кадәрге ай алдыннан килүче соңгы 12 календарь ай өчен гаиләнең һәр әгъзасының керемнәре турында документлар (алар турындагы мәгълүматлар Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондында булган түләүләрдән һәм Россия ЭЭМ түли торган пенсияләрдән тыш), шул исәптән:

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 елның 24 декабрендәге 922 номерлы Карары нигезендә уртача эш хакын исәпләгәндә исәпкә алына торган, хезмәткә түләү системасында каралган түләүләр;

- хезмәт законнарында каралган очракларда саклана торган уртача эш хакы;

- дәүләт яки иҗтимагый бурычларны үтәгән вакытта дәүләт органы яки иҗтимагый берләшмә түли торган компенсация;

- эштән азат ителгәндә түләнә торган пособие, отставкага киткәндә түләнә торган компенсация, оешма бетерелү, хезмәткәрләр саны яки штаты кыскартылу белән бәйле эштән азат ителгәндә, эшкә урнашу чорында саклана торган хезмәт хакы;

- эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнүдән керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат оештырмыйча гына хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне дә кертеп;

- отставкага чыккан судьяларга гомер буена бирелә торган айлык түләү;

- хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары һәм җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре, Россия Федерациясе таможня органнары һәм хокук саклау хезмәтенең башка органнары хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук даими характердагы өстәмә түләүләре һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән азык-төлек белән тәэмин итү;

- Россия Федерациясенең гражданнар законнары нигезендә төзелә торган килешүләр буенча эш өчен түләү;

- социаль түләүләр:

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү оешмаларында укучыларга, фәнни-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге уку рәвешендә укучы аспирантларга һәм югары белем бирү оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына, дини белем бирү оешмаларында укучыларга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм;

хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган һәм баланы 3 яшькә җиткәнче тәрбияләү буенча ялда булган гражданнарга айлык компенсация түләүләре;

контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары белән бергә җирлекләрдә яшәү чорында, эшләмәскә мәҗбүр булган яки белгечлеге буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмау сәбәпле эшкә урнаша алмаган һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган хатынына, шулай ук, медицина оешмасы бәяләмәсе

буенча аларның балалары чит кеше тәрбиясенә мохтаҗ булган очракта, хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары иренең хәрби хезмәт урыны буенча яшәү шартлары белән бәйле рәвештә балаларының сәламәтлеге буенча эшләмәскә мәҗбүр булган чорда айлык пособие;

аларны эшкә урнаштыру мөмкинлеге булмаган ерактагы гарнизоннарда һәм җирлекләрдә Россия Федерациясе эчке эшләр органнары һәм җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкче составы затларының эшләмәүче хатыннарына айлык компенсация түләве;

медицина күрсәтмәләре буенча академик ялда булу чорында студентларга, аспирантларга һәм докторантларга бирелә торган компенсация түләүләре;

хәрби хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре балаларына айлык пособие;

хәрби җыеннарга чакырылган хәрби хезмәткәр яки граждан хәрби хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә һәлак булган (үлгән), яисә хәрби травма нәтиҗәсендә үлгән очракта гаиләсенең һәр әгъзасына түләнә торган айлык акчалата компенсация;

милек хокукында гаиләнеке (аның аерым әгъзаларыныкы) булган мөлкәттән керемнәр, аларга түбәндәгеләр керә:

күчемсез мөлкәтне (җир участокларын, йортларны, фатирларны, дачаларны, гаражларны), транспорт һәм башка механик чараларны, продуктлар эшкәртү һәм саклау чараларын сатудан һәм арендага (наемга) бирүдән керемнәр;

шәхси ярдәмче хуҗалыктан алынган җимешләр һәм продукцияне сатудан керемнәр;

- керемнәрнең башка төрләре, аларга түбәндәгеләр керә:

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарыннан, Россия Федерациясе таможня органнарыннан, хокук саклау хезмәтенең башка органнарыннан азат ителгәндә бер тапкыр бирелә торган пособие;

эш бирүче үз хезмәткәрләренә, шул исәптән инвалидлык буенча яки яшь буенча пенсиягә чыгу белән бәйле эштән азат ителүчеләргә күрсәтә торган матди ярдәм;

Россия Федерациясе авторлык хокукы һәм чиктәш хокуклар турында законнар нигезендә, шул исәптән мираска бирүнең авторлык шартнамәләре буенча алына торган авторлык түләүләре;

акцияләр буенча керемнәр һәм оешма милке белән идарә итүдә катнашудан башка керемнәр;

гаилә әгъзалары ала торган алиментлар;

банктагы кертемнәр буенча процентлар;

мираска бирелгән һәм бүләк ителгән акча;

4) баланың (балаларның) туу акты Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән очракта, баланың (балаларның) туу турында таныклык күчермәсе;

5) ышанычлы затлар өчен, Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч язуының күчермәсе;

6) гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән түбәндәгеләрне раслый торган документ(лар) (ирекле формада):

- аларның персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булуны;

- персональ мәгълүматлар органга яки оешмага тапшырылганда, гариза бирүченең алар исеменнән эш итүгә вәкаләтен;

7) гражданнар хәле актларын теркәү органнарыннан баланың атасы турындагы мәгълүматларны туу турында таныклыкка кертүне нигезләү хакында белешмә;

8) ата-аналар алимент түләүдән качарга тырышкан очракта яисә алимент түләтү мөмкин булмаган очракта, өстәмә рәвештә түбәндәге документларның берсе тапшырыла:

- иректән мәхрүм итү төрендәге җәзаны үти торган учреждениедә җәза үтәү,

кулга алыну, мәҗбүри дәвалауда булу сәбәпле, алимент түләргә тиеш булган бурычлы затның хезмәт хакы булмау турында учреждениедән белешмә;

- Федераль суд приставлары хезмәте органнарыннан алиментлар түләүдән качарга тырышу белән бәйле бурычлы затны эзләү турында карар;

- эчке эшләр органнарыннан җинаять кылган өчен ата-аналарны җинаять җаваплылыгына тарту турында белешмә;

9) хәрби комиссариаттан баланың атасы хәрби хезмәткә чакырылу турында белешмә яки хәрби һөнәри белем бирү учреждениесеннән баланың атасы укуда булу турында белешмә.

9. Вәкаләтле орган ведомствоара электрон үзара эшчәнлек тәртибендә түбәндәге документларны соратып ала:

1) баланы мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган тиешле муниципаль белем бирү учреждениесенә урнаштыру турындагы килешүнең күчермәсе;

2) мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениесендә баланы карау һәм тәрбияләү өчен түләү квитанциясенең күчермәсе;

3) баланың (балаларның) туу акты Татарстан Республикасы территориясендә (ГХАТ органнарында) теркәлгән очракта, балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар;

4) эшсезлек буенча пособие түләү турында мәгълүматлар, эшсезлек буенча пособиеләр эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм башка түләүләр, стипендия һәм мәшгульлек хезмәте органнарының юлламасы буенча һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган матди ярдәм, җәмәгать эшләрендә катнашкан эшсез гражданнарга һәм вакытлыча эшләрдә катнашу чорында социаль ярдәмгә аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга түләүләр, шулай ук 14 тән 18 яшькә кадәрге яшьтәге балигъ булмаган гражданнарга аларның вакытлыча эшләрдә катнашуы чорында түләүләр (дәүләт халык мәшгульлеге хезмәте органнарында);

5) Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пенсияләр, компенсация түләүләре һәм пенсионерларны өстәмә айлык матди тәэмин итү күләме турында мәгълүматлар;

6) эш бирүче (иминиятләштерүче) (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды) тарафыннан физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка бүләкләүләр суммасы турында;

7) пенсия алу, билгеләү, алмау турында һәм түләүләр туктатылу турында (Россия ЭЭМ);

8) социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган бала карау буенча айлык пособие күләмнәре турында мәгълүматлар;

9) социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособие, йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие, шулай ук йөклелекнең иртә срогында медицина учреждениеләрендә исәпкә куелган хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында мәгълүмат;

10) социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган социаль түләүләрнең барлык төрләренә өстәмәләр һәм өстәп түләүләр күләме турында мәгълүматлар;

11) социаль яклау органнары тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары билгеләгән башка социаль түләүләрнең күләме турында мәгълүматлар;

12) опека (попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) тарафыннан баланы карау өчен акча алу турында мәгълүматлар;

13) баланы гаиләгә бирү һәм баланы алучыларга тиеш булган бүләкләү суммасы

турында мәгълүматлар;

14) ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукын чикләү турында мәгълүматлар;

15) медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча аларның һөнәри яктан хезмәткә яраклылыгын югалтуы иминият очрагы барлыкка килү нәтиҗәсе булып торган очракта, эштәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри чирләрдән иминиятләштерелгән гражданнарга яисә иминиятләштерелгән затның үлеме иминият очрагы барлыкка килү нәтиҗәсе булып торган очракта, түләүләрне алу хокукына ия затларга түләнүче мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен бирелә торган иминият түләүләре турында мәгълүматлар;

16) гариза Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән очракта, гариза бирүченең паспорты яраклы булуны раслау турында.

10. Мөрәҗәгать иткән көнгә гариза бирүче гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача керемен исәпкә алып билгеләнгән социаль ярдәм чараларын алучы буларак исәпләнгән очракта, гариза бирүче керемнәр турындагы мәгълүматларны тапшыру бурычыннан азат ителә.

Мөрәҗәгать иткән көнгә гариза бирүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларында баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация турында» 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы Карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләнүче мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларында баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алучы буларак исәпләнгән очракта, гариза бирүче әлеге Тәртипнең 8 пунктындагы 3-8 пунктчаларда күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыру бурычыннан азат ителә.

Вәкаләтле органда мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларында баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алуга хокукын раслаучы мәгълүматлар булган очракта, әлеге компенсация яңа срокка гариза бирүченең мөрәҗәгатеннән башка билгеләнә.

11. Вәкаләтле орган тарафыннан социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү процесслары «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» (алга таба - бердәм цифрлы платформа) дәүләт мәгълүмат системасыннан яки мәгълүмат системаларыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

12. Мәгълүмат системаларында электрон рәвештә социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү өчен вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

1) социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү турында гаризалар (алга таба - гариза) һәм документлар (документларның күчермәләрен, мәгълүматларны) кабул итү, шулай ук гражданнардан кергән гаризаларны һәм документларны (документларның күчермәләрен, мәгълүматларны) эшкәртү;

2) гариза бирүченең социаль яклау (ярдәм) чараларын алуга хокукын раслау;

3) ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып, запрослар формалаштыру һәм мәгълүматлар алу;

4) социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү турында, социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләүдән баш тарту турында, социаль яклау (ярдәм) чараларын түләү турында карар кабул итү, социаль яклау (ярдәм) чаралары күләмен яңадан исәпләү (кирәк булганда), шулай ук алынып бетмәгән сумманы бирү;

5) мәгълүмат системаларындагы мәгълүматлар нигезендә гариза проектын алдан (проактив) әзерләү;

6) социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү, шул исәптән мәгълүмат системаларындагы мәгълүматлар нигезендә гаризасыз тәртиптә яки алдан башкару

(проактив) режимында;

7) социаль яклау (ярдәм) чараларын бирүне туктату яки озайту, социаль яклау (ярдәм) чараларын бирүне туктатып тору һәм яңадан башлау турында карар кабул итү;

8) исәп-хисап - түләү документларын формалаштыру;

9) кредит һәм илтеп бирү оешмаларыннан мәгълүматларны эшкәртү;

10) хисаплылык формалаштыру;

11) мәгълүмат системаларында имзаланган электрон документларны, шулай ук реестр язмаларын саклау.

13. Социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү түбәндәге ысулларның берсе белән гамәлгә ашырыла:

1) гариза нигезендә;

2) социаль яклау (ярдәм) чараларын бирү өчен гражданнарның банк счетлары реквизитлары турындагы мәгълүматлардан файдаланып, гаризасыз тәртиптә (мондый тәртип Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән очракта).

14. Гариза түбәндәге ысулларның берсе белән бирелә:

1) «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба - бердәм портал) аша яки, әгәр бу Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган булса, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталы (алга таба - региональ портал) аша электрон рәвештә. Бердәм портал яки региональ портал аша бирелгән гариза, ачкычы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имзадан файдалану турында» 2013 елның 25 гыйнварындагы 33 номерлы Карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имзадан файдалану кагыйдәләре нигезендә алынган гади электрон имза белән, әгәр аны куллану мөмкинлеге социаль яклау (ярдәм) чараларын бирү тәртибен җайга салучы норматив хокукый акт белән билгеләнгән булса, тикшерү ачкычының сертификаты Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган көчәйтелгән квалификациясез электрон имза яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана;

2) шәхсән:

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә вәкаләтле орган һәм күрсәтелгән килешүләрне төзүгә вәкаләтле күпфункцияле үзәк арасында үзара эшчәнлек турында төзелгән килешү булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк аша;

- Россия Федерациясе законнарында һәм (яки) Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда вәкаләтле органга.

15. Гариза бердәм портал аша бирелгәндә, аны автомат рәвештә «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы мәгълүматлар, шулай ук бердәм портал белән интеграцияләнгән витриналардагы вәкаләтле орган мәгълүматлары белән тутыру тәэмин ителә.

16. Вәкаләтле орган тарафыннан социаль яклау (ярдәм) чаралары бирү турында карарлар кабул итү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны сорату һәм алу ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның

27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1, 6 һәм 6.1 өлешләрнең нигезләмәләрен исәпкә алып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлектә каралган документлардан тыш.

Социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүматлар гариза бирүче тарафыннан социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү тәртибен җайга сала торган, расланган тиешле норматив хокукый актлар, мондый документлар исемлекләре (документларның күчермәләре, мәгълүматлар) нигезендә (барлыкка килгән конкрет тормыш хәленә карап) тапшырылырга мөмкин.

17. Вәкаләтле орган тарафыннан, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып, электрон рәвештә запрослар формалаштыру һәм социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алу автоматлаштырылган тәртиптә тәэмин ителә.

18. Бердәм порталда яки региональ порталда гариза бирү этабында, әгәр бу Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган булса, вәкаләтле органга шәхсән тапшырырга кирәк булган документлар (документларның күчермәләре, мәгълүматлар) исемлеге турында гариза бирүчегә мәгълүмат бирү тәэмин ителә.

Вәкаләтле орган тарафыннан мәгълүмат системаларында электрон рәвештә социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү процесслары гамәлгә ашырылганда, әгәр Россия Федерациясе законнары яки Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү турында яки социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләүдән һәм бирүдән баш тарту турында карарлар кабул итү өчен вәкаләтле орган белгеченең катнашуы таләп ителсә, гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларны (документларның күчермәләрен, мәгълүматларны) карап тикшерү кирәклеген күздә тоткан очраклардан тыш, социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү турында яки билгеләүдән һәм бирүдән баш тарту турында карарларны автомат рәвештә (программа-аппарат чаралары хисабына) әзерләү тәэмин ителә.

19. Компенсация билгеләүне кире кагу өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;

2) гамәлдәге срогы чыккан документлар тапшыру (күрсәтү);

3) закон таләпләрен бозып рәсмиләштерелгән документлар тапшыру.

20. Социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү турында яисә билгеләүдән һәм бирүдән баш тарту турында карар, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тиешле карар кабул итү өчен кирәкле барлык документларны (документларның күчермәләрен, мәгълүматларны) алган көннән башлап икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә, шулай ук:

1) гаризаны вәкаләтле орган тарафыннан теркәү гариза вәкаләтле органга кергән көннән башлап бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;

2) социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алуга вәкаләтле орган тарафыннан ведомствоара запрослар җибәрү вәкаләтле органга гариза теркәлгән көннән башлап бер эш көне эчендә һәм (яки) карамагында социаль яклау (ярдәм) чаралары билгеләү һәм бирү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүматлар булган вәкаләтле органнан ведомствоара запрос җибәрүгә мөнәсәбәтле мәгълүматлар алынган көнне гамәлгә ашырыла (тиешле документлар һәм мәгълүматлар алар карамагында булмаса, вәкаләтле орган тарафыннан ведомствоара запрос җибәрү мөмкин булмаган очракта);

3) ведомствоара электрон запросларга җавап бирү кысаларында (ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып) вәкаләтле орган тарафыннан социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны (әгәр алар аның карамагында булса) тапшыру

срогы вәкаләтле орган тарафыннан тиешле запрослар җибәрелгән вакыттан башлап 48 сәгатьтән артырга тиеш түгел;

4) ведомствоара запросларга җавап бирү кысаларында (ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланмыйча) вәкаләтле орган тарафыннан социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны (әгәр алар аның карамагында булса) тапшыру срогы мондый ведомствоара запрослар алынган көннән башлап 5 эш көненнән артырга тиеш түгел;

5) гаризаны теркәгән көнне вәкаләтле орган тарафыннан гариза бирүчегә, гариза бирүче күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән башлап 5 эш көне эчендә аңа шәхсән (барлыкка килгән конкрет тормыш хәленә карап) тапшырырга кирәк булган документлар исемлеге (документларның күчермәләре, мәгълүматлар) турында мәгълүматны җибәрү гамәлгә ашырыла;

6) гаризада дөрес булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүмат булу факты билгеләнгән көнне вәкаләтле орган тарафыннан гариза бирүчегә, гариза бирүче күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән башлап 5 эш көне эчендә гаризаны эшләп бетерү кирәклеге турындагы мәгълүматны җибәрү гамәлгә ашырыла;

7) социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү процесслары гариза бирүче тарафыннан эшләп бетерелгән гариза, социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү турында яки билгеләүдән һәм бирүдән баш тарту турында вәкаләтле орган тарафыннан карарлар кабул итү өчен кирәкле документларның тулы комплекты (документларның күчермәләре, мәгълүматлар) тапшырылганга кадәр, әгәр федераль законнарда башка сроклар каралмаган булса, 5 эш көненнән артмаган срокка туктатылып торырга мөмкин.

21. Социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү тиешле карарны электрон рәвештә бердәм цифрлы платформада көчәйтелгән квалификацияле электрон имза яки вәкаләтле органның мәгълүмат системасында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (вәкаләтле органның мәгълүмат системасында вазыйфаи затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы) белән имзалап теркәлә.

22. Вәкаләтле орган тарафыннан социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү турында карарлар кабул итү һәм аларны исәпкә алу мәгълүмат системаларында юридик әһәмиятле язмалар рәвешендә гамәлгә ашырыла.

23. Вәкаләтле орган тарафыннан социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү турында карарлар кабул итү бердәм цифрлы платформадан файдаланмыйча гына гамәлгә ашырылган очракта, вәкаләтле орган мондый карарларны бердәм цифрлы платформага автомат рәвештә тапшыруны тәэмин итә.

24. Түләүле эшләр, күрсәтелгән социаль яклау (ярдәм) чарасы буенча акчаларны түләү һәм илтеп бирү турындагы документлар, шулай ук социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләүдән баш тарту турындагы эшләр Россия Федерациясенең архив эше турындагы законнары нигезендә электрон рәвештә саклана.

25. Вәкаләтле орган тарафыннан гражданга социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү процесслары бердәм портал аша яки региональ портал аша гамәлгә ашырылганда, әгәр бу Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган булса, тиешле процессны гамәлгә ашыру көнендә түбәндәге мәгълүматны җибәрү тәэмин ителә:

1) гаризаны карап тикшерүне туктатып тору һәм яңадан башлау турындагы мәгълүматны да кертеп, гаризаны карап тикшерү барышы турында, социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү тәртибен регламентлаштыра торган норматив хокукый актлар нигезләмәләрен дә кертеп, гаризаны карап тикшерү нәтиҗәсе һәм вәкаләтле орган тарафыннан социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм бирү турында яки билгеләүдән һәм бирүдән баш тарту турында (баш тартуның дәлилләнгән сәбәбен күрсәтеп) кабул ителгән карар турында;

2) гаризада дөрес булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүмат булу факты

ачыкланган очракта, гаризаны эшләп бетерү кирәклеге турында;

3) гражданның акча күчерү гамәлгә ашырылган банк счетын күрсәтеп, акча күчерү турында яки банк счеты реквизитларын үзгәртү өчен, гамәлләрне күрсәтеп, акча күчереп булмау турында.

26. Бердәм портал аша яки региональ портал аша, әгәр бу Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган булса, гражданга социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләүгә һәм бирүгә мөнәсәбәтле мәгълүмат җибәргәндә, вәкаләтле орган түбәндәгеләргә бурычлы:

1) социаль яклау (ярдәм) чарасын билгеләү һәм бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актта билгеләнгән социаль яклау (ярдәм) чарасын билгеләү һәм бирү шартлары үзгәргән очракта, социаль яклау (ярдәм) чараларын алучыларга хәбәр итәргә;

2) социаль яклау (ярдәм) чарасы конкрет чорга билгеләнгән очракта, социаль яклау (ярдәм) чараларын алучыларга социаль яклау (ярдәм) чарасын бирү срогы тәмамланырга бер ай кала аны бирү срогының тәмамлануы якынлашу турында, шулай ук билгеләнгән социаль яклау (ярдәм) чарасын озайту өчен кирәкле шартлар турында хәбәр итәргә.

27. Россия Федерациясе законнарында яки Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда, әлеге Тәртипнең 23 һәм 24 пунктларында каралган мәгълүмат гражданга язма рәвештә җибәрелергә мөмкин.

28. Компенсация барлык тиешле документлар белән бергә гариза тапшырган айдан башлап билгеләнә һәм 6 ай дәвамында түләнә.

29. Компенсация суммасы гариза бирүченең банк счетына күчерелә.

Банкта счет ачу һәм аннан файдалану мөмкинлеге булмаган гариза бирүчегә компенсация түләү (илтеп бирү) элемтә оешмасы аша гамәлгә ашырыла.

30. Компенсацияне банк счетына күчерү һәм почта элемтәсе аша илтеп бирү исәп-хисап ае дәвамында башкарыла.

31. Физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан күчерелгән түләүләр һәм башка бүләкләүләр суммасы турында мәгълүматлар, компенсация билгеләү гариза бирүченең гаризада күрсәтелгән ризалыгы белән, ул компенсация билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән айдан алдагы 12 айның соңгы 6 ае өчен, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан алынган мәгълүматлар нигезендә башкарыла.

32. Түләү тукталуга китерүче хәлләр (белем бирү оешмасын алыштыру, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, гариза бирүченең вафат булуы) барлыкка килгәндә, әлеге хәлләр булган айдан соң килүче айдан түләү туктатыла.

33. Күрәләтә ялган мәгълүматларны үз эченә алган документлар тапшыру, өстәмә компенсация алу хокукына йогынты ясаучы мәгълүматларны яшерү нәтиҗәсендә артык түләнгән компенсация суммалары гариза бирүче тарафыннан ирекле рәвештә, казначылыкта вәкаләтле орган исеменә ачылган счетка күчерү юлы белән кире кайтарыла, ә гариза бирүче баш тарткан очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә түләтелә.

34. Гражданнар тарафыннан торак һәм коммуналь хезмәтләргә түләү өчен алдан билгеләнгән субсидия яисә балага ай саен бирелә торган пособие алынган очракта, гражданның гаризасы буенча компенсация субсидия яисә балага ай саен бирелә торган пособие бирү срогы тәмамланганга кадәр билгеләнергә мөмкин.

Әгәр компенсацияне алучы торак һәм коммуналь хезмәтләргә түләү өчен субсидия яисә балага ай саен бирелә торган пособие билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән гражданның гаилә составына керсә, алдан билгеләнгән компенсация аны алучының гаризасы буенча, субсидия яисә балага ай саен бирелә торган пособие алучы тарафыннан тапшырылган документларны исәпкә алып, субсидия яисә балага ай саен бирелә торган пособиене алу чорына яңадан билгеләнергә мөмкин.

35. Вәкаләтле органның гаебе буенча үз вакытында алынмаган компенсация, узган вакыт өчен чикләүсез срокта түләнә.

36. Гариза бирүче вафат булган очракта, исәпләнгән, ләкин исән вакытта аңа түләнмәгән компенсация суммалары мирас составына кертеләләр һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гомуми нигезләр буенча мирас ителәләр.

37. Компенсация бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева